ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2022 г. Казань № 311-23/тэ-2022

Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре кулланучыларына «Таткоммунэнерго» республика житештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 9 ноябрендәге 34-ПР номерлы идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре кулланучыларына «Таткоммунэнерго» республика житештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Таткоммунэнерго» РЖБ» АҖ) тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.11.2022 № 311-23/тэ-2022
карарына кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре кулланучыларына
«Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ тарафыннан җибәрелә торган
җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукциялəнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре кулланучыларына «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 09.11.2022 №311-23/тэ-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр | 1 793,86 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 09.11.2022 №311-23/тэ-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр | 2 152,63 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге